Ул халыкчан, җор телле, юмор белән драматизм бергә бара).

- Хәзер китапларыгызны ачыгыз. Кайсы урыннарда сурәтләү чаралары таптыгыз, нинди мәкальләр, фразеологизмнар, гореф-гадәтләр, йолалар, сатира элементлары белән очраштыгыз? (Укучылар алдан үзләре табып килгән урыннарны укып күрсәтәләр).

- Әсәрдә кайсы милләт кешеләре турында сүз бара? (Татар милләте вәкилләре турында).

- Милләтебезнең яшәеше, телебезнең, гореф-гадәтләребезнең, йолаларыбызның сакланышы нинди сыйфатлы кешеләргә бәйле? (Намуслы, кешелекле, ярдәмчел, эшчән, бердәм, сабыр, әхлаклы кешеләргә бәйле).

- Нинди кешеләр тормышта үз урыннарын табалар? (Милли әхлаклы, халыкның гореф-гадәтләрен, йолаларын саклап яшәгән һәм киләчәк буыннарга тапшырган кешеләр тормышта аякларына ныклы басып торалар, үзләреннән соң җир йөзендә матур җыр, изге васыять калдыра алалар).

- Әсәрдә авторның тагын бер фикерен сиземләргә мөмкин. Ул милләтнең чын йөзе кайда сакланган дип әйтергә тели? (Авылда сакланган.)

- Әйе, милләтнең яшәеше һәм киләчәге авыл белән бәйле, ди автор, авылның милләт сакчысы икәнлегенә басым ясый. Әйтергә кирәк, авыл тормышын М.Мәһдиев кебек оста сурәтләүче, бөтен нечкәлекләрен белеп тасвирлаучы язучылар күп түгел. Әйе, тоталитар режим белән яшәсә дә, шул чордагы авыл иң кыйммәтле мирасыбызны саклап кала алды, безнең буыннарга кадәр җиткерде. Ә хәзерге авылның хәле ничек соң? Анда нинди тискәре күренешләр килеп керде? (Әчүчелек, колхозлар таркалу, урбанизация тәэсире һ.б.)

*IV. Дәресне йомгаклау.*

Янадан эпиграфка әйләнеп кайтабыз. Кеше кая китә соң? (Кеше мәңгелек түгел, ул фани дөньяга күчә.)

Нәтиҗә: җирдә кешенең җыры өзелмәскә тиеш, милләт баласы бишек җырын ишетеп үсәргә тиеш. Җыр — кешенең мәңгелек юлдашы.

Билгеләр кую.

*V. Өй эше.* «Мин киләчәктә милләтемне ничек күз алдына китерәм?» исемле темага инша язарга.

Хәзерге вакытта сакланып калган гореф-гадәтләр, йолалар, ырымнар турында язып килергә.

Чыганак: Фән һәм мәктәп=Наука и школа. – 2007. – № 10. – Б. 50-52.

# ЯШӘ, БОРЧУЛЫ ҖАНЫМ

*Г. Мөхәммәтгәрәева, Түбән Табын урта мәктәбе укытучысы, Мөслим районы*

Сәхнә яки кичә үткәреләсе зал тиешенчә җиһазлана.

"Арча" көе яңгырый.

<u>1 нче алып баручы</u> көй фонында С.Хәкимнең «Арчалылар бит без» шигырен укый.

<u>2 нче алып баручы.</u> Шундый төбәкләр була: җире дә, урман-болыннары да җитәрлек, халкы да тырыш, һөнәрле, укымышлы, сәләтле. Күпме язучы, шагыйрь, галим, җырчы, биюче, бер төбәктән. Татарстан җирендә шундый төбәкләрнең берсе — Арча ягы. 20 дән артык язучы, шагыйрь, 25 тән артык галим, дистәдән артык җырчы, артист биргән як бу.

Революциягә кадәр үк мәктәп-мәдрәсәләре (аеруча Кышкар, Ташкичү мәдрәсәләре) белән дан тоткан.

Үзеннән-үзе биеп китә торган читекләре, чигүле чүәкләре генә ни тора Арчаның! Заманында күпме Хезмәт Геройлары, хезмәт алдынгылары бирән як бу! Татар дөньясына бөек Тукайны, зур галимнәр Курсави, Күлтәси, Мәрҗанине, талантлы каләм ияләре М.Галәүне, Г.Бәшировны, М.Мәһдиевне, Г.Ахуновны, Р.Төхфәтуллинны, зур шагыйрь Сибгат Хәкимне биргән бу як!

<u>1 нче алып баручы.</u> С. Хәким — Казан артыннан, Әтнә районы Күлле-Киме авылыннан (берара Әтнә Арчага кушылып яшәде, үзгәртеп кору елларында кабат район статусы алды). Монда аның бала чагы, үсмер чагы, егет чагы узган.

Булачак шагыйрь крестьян Хәким һәм Газзә апа гаиләсендә туа. Атасы Хәким абый озын буйлы, сары мыеклы, матур, пөхтә кеше була. Сүзгә дә, эшкә дә бик оста була ул. Әнисе Газзәбикә апа исә әчкерсез, кешелекле, сабыр, уенкөлке ярата торган, олы җанлы, туры сүзле — "туры Газзә" булган.

Туры Газзә диләр иде аны,
Кем үз зарын аңа түкмәде.
Әмма бер дә җене сөйми иде
Гайбәтне һәм юк-бар үпкәне.

Сибгат Хәким

2 нче алып баручы. Күллә-Киме мари иле белән чиктәш. "Мари ягы — урманлы як. 1921 елгы ачлыкта без шул мари авылларына сыендык. Шактый бәрәңге ташыдык без ул яктан. Ә бәрәңге булса, ничек тә булса җан асрап була", — дип яза соңыннан әдип.

Хәким абый - балта остасы. Күпме йортлар салган ул! 1921 елгы ачлыкта, гаиләсен саклап калу өчен, мари ягына йөри, үзе белән кечкенә Сибгатне дә ала.

1 нче алып баручы. "Алар эшли, мин йомычкалар арасында уйнап утырам. Алар көндез чәйгә керә, мин ишек алдында калам. Әмма эти малае барын онытмаган. Онытса, ул миңа тәбикмәк алып чыгып бирмәс иде. Их, ул кайнар арыш тәбикмәге, ансат кына килеп кермәгән икән минем кулга".

*"Тәбикмәк" шигыре.*

2 нче алып баручы. Хәким абый үзенең олы улы белән ачлык елны Украина якларына бәхет эзләргә чыгып китә. Алар икесе дә тиф авыруыннан вафат булалар. Сибгат бабасы белән кечкенә сеңлесенең ачтан шешенеп үлүләрен үз күзләре белән күрә. Күптән сыналган бер нәрсә бар: язучы булу нияте, күпчелек очракта, фаҗигадән, кешеләргә ни дә булса әйтергә теләүдән туа. Малай чагында «кичергән фаҗигасе үсмер Сибгатне тетрәтеп, аның ерак бабаларыннан ук килгән күңел байлыгын кузгатып җибәргәндер.

Күтүчеләр тапкан чишмә кебек,
Җырым минем, син дә улаксыз.
Шул чишмә күк син дә тыныч актың,
Шул чишмә күк син дә гөнаһсыз.

1 нче алып баручы. Үз авылларында 7 еллык мәктәпне тәмамлаганнан соң, ул пионервожатый булып эшли, комсомолга керә. Бераздан Казанга китә, рабфакта укый (1931-32 еллар). Алга таба укуын Казан дәүләт педагогия институтында дәвам итә. Югары белем алгач, С.Хәким Татарстан китап нәшриятында редактор, «Совет әдәбияты» журналында әдәби хезмәткәр була.

Рабфакта укыганда ук әдәби түгәрәккә бик теләп йөргән Сибгат 1938 елда "Беренче җырлар" исемле шигырь китабын чыгара. Бөек Ватан сугышына кадәр С.Хәким шактый шигырьләр, "Шагыйрьнең балачагы", "Пар ат" поэмалары (Г.Тукайга багышланган) авторы.

**Учак**

Яр буенда ялгыз бер ут яна,
Кем ял иткән анда? Кем яккан?
Туктап мин дә җыеп чыбык салдым,
Аерылуы кыен учактан.
Ташлап китәр идем - бик кызганам,
Сүнәр көйрәп торган күмере.
Яңадан соң аны кем тергезә,
Дәвам итсен өчен гомере.
Шигырь итеп яздым сине, учак -
Син күпмегә кадәр яшәрсең?
Тиз сүнәрлек булсаң, мин янымда,
Кабызырмын, миңа дәшәрсең!

1939 ел

2 нче алып баручы. Сугышка кадәр С.Хәким М.Җәлил, Г.Кутуй, Ш.Маннур, Ә.Исхак, Г.Кашшаф кебек каләм иярләре белән таныша, дуслаша, ә Х.Туфан белән дуслыклары гомер буе дәвам итә.

1938 елда С.Хәкимнең "Юксыну" шигыре яшьләр газетасында басыла. Шагыйрьнең улы Рафаэль Хәким болай дип искә ала: "Шигырьнең язылу тарихы кызыклы гына. Ул әнием белән бәйле. Әтием белән алар бер-берсен ошатып, яратып йөрсәләр дә, әнинең бераз ялындыра торган гадәте булган. Араларында аңлашылмаучылык килеп чыга. Алар бер ай чамасы очрашмый торалар. Шуннан соң әни яшьләр газетасында әтинең шушы шигырен укый һәм бик шатлана". Шагыйрьнең сөйгәне Мөршидә Вильданова — һөнәре буенча фельдшер-акушер — шигырьләр дә язган. Сугышка кадәр "Чиккән яулык" исемле шигырь китабы да чыгара. "Минем шушы шигырь ятратуым шагыйрьләр арасына кертте дә. Шулай итеп, гомерлек ярымны да шагыйрьләр арасыннан сайладым", — дип яза ул.

*"Юксыну" шигыре.*

1 нче алып баручы. Бөек Ватан сугышы елларында бу шигырьне композитор Шакир Мәҗитов көйгә сала. Шигырь сугышка сөйгәннәрен озаткан кызлар, хатыннар рухын чагылдыра, шунлыктан ул бик популярлашып китә. Җырның беренче башкаручысы — Зифа апа Басыйрова. Ул аны һәр концертында җырлый. С.Хәким сугыштан Казанга кайткач, аны урамда Зифа апа күреп ала да: "Әле син үз сүзләреңә җыр язылганын белмисеңдер! Әйдә әле, җырлап күрсәтим", — дип радиокомитетка алып керә, җырлап күрсәтә. "Юксыну" белән шагыйрь иҗатында җыр жанры башланып китә.

*З.Басыйрова язмасында "Юксыну" җыры.*

Сәхнәгә егет чыга. "1939 елның декабре. Тукай урамы, мехчылар клубы каршындагы йортларның берсендә минем туй, яшьлекнең туе. Буранлы көн. Капка төбендә торам, кунакларны каршылыйм. Беренче кеше - Гадел Кутуй. Буран эченнән елмаеп, балкып, бусагадан ук ямь алып керүче Кутуй. Аннары Шәйхи Маннур, Муса Җәлил...

Язучыларга бай иде бу мәҗлес: Гази Кашшаф, Әхмәт Исхак. Бер читтә һәрвакыт язып утыручы Х. Туфан. Берничә айдан Туфаннан аерылдык. Каләменең очы белән генә латинча бик вак итеп, яшел кара белән язган шигыре калды".

*"Минем сугыштан соңгы туйда" шигыре.*

2 нче алып баручы ("Изге сугыш" җыры яңгырый). 1941 ел. 22 июнь. Бөек Ватан сугышы башлана. Запастагы взвод командиры С.Хәкимгә, сугыш башланып ике көн үтүгә, повестка тоттыралар. Шуннан башлап, сугыш беткәнче ул фронтта. Калинин фронты... Ржев, Белгород өлкәсе, атаклы Курск дугасы. "Мин еш кына 1943 елның июль аен искә алам. Юк, шагыйрь булып түгел, ә взвод командиры сыйфатында. Миңа атаклы Курск дугасында барган сугышларда башыннан ахрына кадәр катнашырга туры килде. Бу сугышларда мин, үз гомеремдә беренче тапкыр дисәм дә ялгыш булмас, кешеләрне таныдым, совет кешеләренең көчле, бөек рухына сокландым", — дип искә ала.

1 нче алып баручы. Сугыштан соң, 1948 елда, шагыйрь, "Курск дугасы", 1968 нче елда "Дуга" поэмаларын язып, сугыш хатирәләрен яңарта. (Курск сугышын чагылдырган кинофрагментлар күрсәтергә мөмкин.)

*"Дуга" поэмасыннан өзек.*

1 нче алып баручы. С.Хәким сугыштан исән, ләкин бик йончып, авырып кайта. Авырлыгы 47 кг була. Врачлар да өметләнерлек сүзләр әйтмиләр. Хатыны Мөршидә апа, әнисе Газзә апа (ул үләннәр белән дәвалый белгән) тырышлыгы белән исән кала.

*"Әнкәй" шигыре.*

2 нче алып баручы. Сугыштан соңгы еллардан башлап С.Хәким татар шигъриятенең иң абруйлы, иң актив, иң тәэсирле шагыйрьләреннән берсе булды. Үзе дә шигырь остасы иде, башкалардан да шуны таләп итте. Аның матбугатта дөнья күргән һәрбер шигырь бәйләме, һәрбер шигырь циклы, һәр поэмасы олы әдәби вакыйгага әйләнде. Халыкчан, тормышчан иде аның лирик шигырьләре. Ул, чыннан да, шигырь остасы иде. Шуңадыр, бәлки, аның күпме шигырьләре, җырга әйләнеп, халык күңелендә урын алды.

*"Фазыл чишмәсе", "Таң атканда" (халык көйләре), "Ага чишмә" (Ф.Мортазин көе), "Әй,язмыш, язмыш", "Сусау" (С.Садыйкова көе).*

1 нче алып баручы. С.Хәким иҗатында кызыл җеп булып сузылган темалары: туган як, туган җир, Татарстан, Ленин (ул юлбашчы турында ике поэма,берничә шигырь иҗат итә), Тукай.

*"Республикам минем — Татарстан", "Күңелем Ленин белән сөйләшә", "Тукайга" шигырьләре.*

Җырчы В. Гыйззәтуллина язмасында "Таныш өянкеләр" җыры.

2 нче алып баручы. С. Хәким безнең искиткеч зур шагыйребез иде, чын мәгънәсендә халык шагыйре. Ул бервакытта да бернигә дә битараф булмады. Ул гомере буе татар дип җан атты, әдәбимилли тормышыбыз үзәгендә кайнап яшәде. Иҗатында да, тормышында да газиз халкы, газиз республикасы өчен ут йотып яшәде. Үзе исән чагында ук 60 тан артык китабы чыга... Ул Россия Федерациясенең М. Горький исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1970 ел, Ленин турындагы поэмалары һәм соңгы еллардагы иҗаты өчен), Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстанның халык шагыйре, Ленин ордены кавалеры.

1 нче алып баручы. "Васыять" шигыре.

Миннән дә бер җырчы чыкмасмы дип,
Җырлап карар өчен килдем дә
Кире китәм; кайтарыгыз мине
Киме зиратына, Кимегә.

Аның гомере 1986 елның җәендә өзелде. "Кимегә кайтарыгыз", — дисә дә, аны Казандагы татар зиратына куялар.

Мин киткәч тә дөнья матур булыр,
Моңсуланыр Аккош күле генә...
Аккош булып бер кайтырмын әле,
Ышанмагыз минем үлемемә.

Разил Вәлиев

2 нче алып баручы. Бөек Тукаебызның "Мөбәрәк тәсбих өзелде" дигән мәкаләсе бар. С. Хәким турында да шулай әйтә алабыз. Әмма аның шәкертләре, эшен дәвам итүчеләре калды. Шагыйрь өчен моннан да зур бәхет буламы?